ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БӘЗӘКӘ АВЫЛЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 2 декабреннән № 5

«Россия Федерациясендә җирле үз идарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үз идарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкәавылҗирлеге Бәзәкәавылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда үз ара салым акчасын 300 сум күләмендә кертергә, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар өчен бер тапкыр түләүдән тыш аның күләмен 150 сум итеп билгеләргә.

2. Җыелган үз ара салым акчаларын җирлеә һәм ияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Бәзәкә авылында вак таш сатып алу, илтеп җиткерү һәм тигезләү хезмәтләре күрсәтү
- Бәзәкә авылында су белән тәэмин итү челтәрләре өчен задвижкалар сатып алу ;
- Бәзәкә авылында кышкы чорда юлларны кардан чистарту
- Бәзәкә авылында Бөек Ватан сугышы һәйкәлен ремонтлау (стеланы тышлау, территорияне төзекләндерү);
- Авыл җирлеге ихтыяҗлары өчен бензин генераторы сатып алу;
- Бәзәкә авылында су алу скважиналарына дистанцион идарә урнаштыру.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Бәзәкә авылы мәгълүмат стендларында урнаштырырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatar.ru «Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов